СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.08.2023 с. Сарманово № 153

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 12 декабрендәге 55 номерлы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекнең 5 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

2) 7 бүлекнең 7 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

3) 13 бүлекнең 7 пунктында «ышанычлы булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль районы
Совет рәисе Ф. М. Хөснуллин